ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**17.12.2024**

Зеленодольск шәһәре

**КАРАР**
**№ 4785**

«Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 03 апрелендәге «Айныткыч» муниципаль казна махсуслаштырылган учреждениесе хезмәткәрләренең хезмәтен оештыру һәм аларның хезмәт шартлары турында» 952 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Айныткыч» муниципаль казна махсуслаштырылган учреждениесе хезмәткәрләренә түләүне камилләштерү максатларында, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. «Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 03 апрелендәге «Айныткыч» муниципаль казна махсуслаштырылган учреждениесе хезмәткәрләренең хезмәтен оештыру һәм аларның хезмәт шартлары турында» 952 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 нче кушымтадагы «Айныткыч» муниципаль казна махсуслаштырылган учреждениесе хезмәткәрләренең хезмәтен оештыру һәм аларның хезмәт шартлары турында нигезләмәнең 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. «Айныткыч» муниципаль казна махсуслаштырылган учреждениесе хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Хезмәткәр вазыйфалары | Вазыйфаи оклад, сум |
|---|---|
| Начальник | 28 000 |
| Начальник урынбасары | 24 000 |
| Баш белгеч | 16 500 |
| Әйдәп баручы белгеч | 14 000 |

2. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

3. Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат (http://pravo.tatarstan.ru ) порталына һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск

муниципаль районының рәсми (www.zelenodolsk.tatarstan.ru ) сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче З.Ф. Хәбибуллин